| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 февраль № 93

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 10 декабрь, 974 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 10 декабрь, 974 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган торак булмаган фонд белән идарә итү һәм аны эксплуатацияләү буенча дәүләт эшләренә норматив чыгымнарга түбәндәге эчтәлекле 9.3 нче пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «9.3 | «Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | 126 776,41»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарга түбәндәге эчтәлекле 7 бүлек өстәргә:

| «7. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы учреждениеләре | | | |
|---|---|---|---|
| 7.1. | «Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәт күрсәтү | 214,56»; |

Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күләмнәре нормативларына түбәндәге эчтәлекле 7 бүлек өстәргә:

| «7. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы учреждениеләре | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7.1. | «Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәт күрсәтү | кеше/көн | 54 675». |

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\93.doc